ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2020 № 486

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 маендагы 578 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль учреждениеләр һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 27 февралендәге 149 номерлы карарыннан чыгып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 маендагы 578 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга тиеш..

3. Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең архитектура һәм шәһәр төзелеше буенча урынбасары О.А. Никитинага йөкләргә.

Җитәкче урынбасары Л.Ф. Нургаянов